**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 1 март № 126

г. Казань

Юридик затларның 2015 елгы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының берләштерелгән коллегиясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм юридик затларның 2015 елгы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының берләштерелгән коллегиясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Юридик затларның 2015 елгы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының берләштерелгән коллегиясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен (кararга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның гамәле 2016 елның 1 феврaленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\126.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 март, 126 нчы карары белән расланды

**Юридик затларның 2015 елгы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының берләштерелгән коллегиясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм юридик затларның 2015 елгы эш йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының берләштерелгән коллегиясен оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү механизмын (алга таба – чара, субсидия) билгели.

2. Субсидия тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Субсидия түбәндәге шартларга җавап биргән юридик затларга аларның оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә (дәүләт учреждениеләреннән (муниципаль учреждениеләрдән) тыш) бирелә:

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булу һәм эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

үзгәртеп оештыру, ябылу яки банкротлык стадиясендә булмау;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларга мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмау (билгеләнгән тәртиптә бурычларның структурасын үзгәртү турында килешү төзегән, бурычларны түләү графикларын үтәүче һәм гамәлдәге түләүләрне үз вакытында гамәлгә ашыручы субъектлардан тыш);

субсидия бирүгә заявка (алга таба – заявка) тапшырган датага уртача айлык эш хакы дәрәҗәсен Татарстан Республикасы буенча эшкә яраклы халык өчен билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән азрак булмаган күләмдә саклау;

бирелгән бюджет акчасыннан максатчан һәм (яки) нәтиҗәсез файдаланмауны элегрәк булдырмау.

4. Субсидия алу өчен юридик затлар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарның исәп-хисапларын һәм нигезләмәсен теркәп, Министрлык раслаган форма буенча заявка;

чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнар сметасы;

юридик затны гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга карата барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләрен.

5. Юридик затлар үз ихтыярлары буенча Министрлыкка түбәндәге документларны кертергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдәтнамә күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында шаһәдәтнамә күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмауны раслый торган документ.

6. Юридик зат бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларны кертмәгән очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәтибендә соратып ала.

7. Министрлык:

заявкаларны кертелгән көнне бит саннары куелган, тегелгән һәм мөһер белән расланган булырга тиешле журналда терки;

заявканы теркәгән көннән соң бер эш көне эчендә кертелгән документларны әлеге Тәртипнең 4 нче пункты нигезендә карап тикшерә;

әлеге пунктның өченче абзацында билгеләнгән вакыт чykканнан соң бер эш көне эчендә субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм заявка бирүчегә бу турыда хәбәр итә.

8. Субсидиядән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында каралган документларның тулы булмаган комплектын кертү;

заявка бирүченең әлеге Тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

9. Субсидия бирү Министрлык һәм аңа карата субсидия бирү хакында карар кабул ителгән юридик зат (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән субсидия бирү турындагы килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турында килешү субсидия бирү хакында карар кабул ителгән көннән соң ике эш көне эчендә төзелә.

Субсидия бирү турындагы килешү формасы Министрлык тарафыннан раслана.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, чараны оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнар төрләре, агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары, Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын, субсидия алучының әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турындагы нигезләмәне үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга субсидия алучының ризалыгы күздә тотыла.

10. Министрлык субсидияне субсидия алучы тарафыннан чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны гамәлгә ашыруны раслый торган документлар

кертелгән көннән соң ун эш көне эчендә субсидия алучының россия кредит оешмасында ачылган хисап исәбенә күчерә.

11. Субсидияне алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү факты ачыкланган очракта, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы субсидияне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарырга тиеш.

12. Субсидия бирү турындагы килешү белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемена субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 11 нче һәм 12 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Министрлык бу Тәртипнең 11 нче һәм 12 нче пунктларында билгеләнгән субсидияне кайтару вакытлары чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча законнар белән билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

14. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерүне законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

F:\KARAR\2016\126.docx